**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

27 ноябрь, 2023 ел № 1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2022 елның 25,26 ноябрендә узган гражданнар җыенының 7 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Яңа Арыш авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алу;
- транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- кышкы чорда Яңа Арыш авылында юлларны карап тору;
- скважинаны рәсмиләштерү өчен түләү;
- ЭЦВ насосы сатып алу:

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Х.С.Зарипов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Х.С.Зарипов